

Ботен жирдә кvп. Вак бәрәнге юк диярлек, ә эре тамыразыклар барлык рекордларны куя: бер килограмм һәм аннан да югарырак зурлыктагылары элэгә. Хәтта кочакка куеп жыя торганнарын Лэмберә районы Татар Тавласы авылында гомер итvче Наиль Касим улы Ряхмятуллов жыйган. Унжиде чилэк чәчкән булса, 160 чилэк жыйган. - Бәрәнгегез бармы – бирәм, ди язма героем. Быел берничә яна сорт-ны чәчеп карадым. Бик ундырылышлы булдылар. Киләсе елга орлыкка калдырырга уйлыйм. Тәмле бәрәнге булып чыкты. «Голландский» сортлыларынын берсе: бер кило орлыктан жиде чилэк бәрәнге жыеп алдым. Бәрәнге ындырыма 17 чилэк утырткан идем, 160 чилэк уныш жыеп алдык. Орлыклыгым белән бергә ашарга дип кышлыкка базга кирәк кадәр салырмын дип уйлыйм, балаларыма шәһәргә биреп жибәрермен һәм калганын асрый торган малларыма ашатырга жыенам,- дип фикерләре белән уртаклашты мәрхvмә әнисе Зәхибә апа тосле тырыш һәм булдыклы Наиль Касим улы Ряхмятуллов.
Мордовиянен торле район торак пунктларындагы ниндирәк хәлләр икән, кvз салыйк. Рузаевка районы Татар Пешлә авылы халкы да кvп иттереп бәрәнге жыеп алганнар. Мәсәлән, Кадрия Спартак кызы Овчинникова бер чилэк чәчкән булса, ун чилэк бәрәнге унышы жыйган; кызыл һәм сары «Голландский» сортлар бигрәк ундырылышлы, ә ак тостәге бәрәнге - «Невский» дигәне, ундырышы буенча калыша. Ул: «Яшелчәчеләр крахмал бvлбеләре кызган вакытта кvнелсез хисләр кичерсәләр, бvген бәрәнге унышларын кая куярга дип баш ватучыларыбыз да бар. Рузаевка базарында бер чилэк бәрәнгенен бәясе 80 сум. Шәхси мин vзем, гаиләм очен чак кына утыртам, ә быел котмәгән уныш булды; исән-сау ашарга язган булсын», - ди кешелекле Кеше - Кадрия Спартак кызы.
Дунгызлар елы - һәрвакыт икенче икмәккә унышлы, диләр. Гороскопка рәхмәт - бу елда да югалмабыз. Икенче проблема хәзер участок хужаларынын кvбесенә тынычлык бирми - мондый бәрәнгене кая куярга? Русьта бу проб-лема тирән тамырларга ия: уныш юк - начар, зур уныш - кая куярга? «Призыв» журналистлары да бу мәсьәләгә жавапны район кvләмендә ничегрәк хәл ителә икәнен язган.
Чирмеш авылында гомер итvче Татьяна Борисовна Тимкаева болай ди: «Мин хәзер бәрәнгене бик аз утыртам. Калган жиргә кvпьеллык vләннәр чәчтек - терлек асрыйм - тупас азык кирәк. Бәрәнгегә килгәндә, аны бvген vстерv - бушка хезмәт. Элек бәрәнгене Марьяновка спирт заводына тапшырырга була иде. Хәзер андый хәл юк».
- Саранскка тоташа язган Берсеневка авылында бәрәнге сату белән проблема юк, чонки

аны утыртудан туктадылар дип әйтергә була, - ди элеккеге мәктәп директоры, авыл жирлеге башлыгы, ә хәзер пенсионер Валентина Викторовна Стрягина. – Ботен эш шунда ки, әгәр уныш мул икән, vстерелгән унышны куяр урын юк. Ә бит заманалар да бар иде, бәрәнгенен кешеләргә яхшы табыш китерvен яхшы хәтерлим. СПК «Пригородное» эшләгәндә, кешеләр «икенче икмәк» vстерv очен кvбрәк жир алырга тырыштылар. Бәрәнгене спирт заводларына, ашханәләргә тапшырырга момкин иде. Мондый хәл кvптән юк инде. Ә башка авыл кешеләре болай фикер йортә: «Эверест»та яки «Магнит»та ел әйләнәсе сатып алып була һәм чагыштырмача арзан булганда, vзенне артык мәшәкатьләр белән нигә мәжбvр итәргә? Шуна кvрә кышка да яшелчә запасын әзерләvдән туктыйлар. Мин vзем инде кvптәннән vзем очен генә утыртам.
Тагы бер фикер: «Ирем белән йоз кырык чиләк бәрәнге жыйдык; бvлбеләр әйбәт, эре, әмма кая куярга? - Болотниково авылында яшәvче Надежда Николаевна Тараскина фикерләре белән уртаклаша. - Биш ел элек безгә Әстерхан эшмәкәрләре килгән иде. Бәрәнгене арбузларга алыштырдык. Бу бик vк отышлы булмаса да, кешеләр риза иде, чонки продукцияне башка сатып булмаган. Ә базарда ботен кеше дә сәvдә итә алмый. 1987 елдан бирле мин авыл советы рәисе булдым. Ул чакта безгә район һәм республикадан жаваплы затларны беркеткән иделәр, ә без - кемнен кvпме бәрәнге сата алачагын, графикны тозедек. Аннары предприятиеләр транспорт жибәреп, шунда ук бәрәнге сатып алдылар. Бу авыл халкы очен бик унайлы иде. Бvген андый хәл юк инде. Шуна бәяләр дә кими. Башта бер чиләк бәрәнге 250 сум тора иде, хәзер инде 100 сумга саталар һәм кvпләр шуна да бик шат, бары тик сатылсын гына».
Бәрәнге яхшы унса да, аны сатарга урын юк. Совет чорын ничек искә алмыйсын?! Чит илдә житештерелгән яшелчә тутырылган кибет киштәләрен кvрvен кызганыч. Ирексездән сорау килеп баса: vз игенчеләреннән сатып алуга караганда, чит илләрдән шул ук бәрәнгене алып килv очсызракмы?

**Н. Хәлил**